
“Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Әбрар Сәгыйди исемендәге Кошман төп гомуми белем бирү мәктәбе”
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

# Татар мәгърифәтчеләре һәм аларның татар мәгарифен үстерүдәге роле



**Төзеде:**
биология, химия
укытучысы
Сабирова Гөлшаһидә

Кошман, 2017

Татар педагогик фикеренең башлангыч нигезләре борынгы **төрки каһанлыгы** чорына ук барып тоташа.

Борынгы төркиләрнең педагогик фикер үсешендә дини һәм дөньяви белем бирү,

әхлак тәрбиясе,

физик һәм экологик тәрбия бирү зур урын алып тора.

# Актуальлек

- Яңа федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә укыту процессында да мәгърифәтчеләребезнең бай мирасына таянып эшләгәндә белем бирүдә югары нәтиҗәлелеккә ирешергә мөмкин.

- **Максат**: татар мәгърифәтчеләренең бай мирасын өйрәнү, күренекле мәгърифәтчеләребезнең педагогик карашларын ачыклау һәм, бүгенге көн таләпләренә туры китереп, үземнең укыту-тәрбия эшемдә куллану.

Мәгърифәтчеләрнең табигать циклы фәннәрен укытуга карашлары турындагы фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.


# **Турфан язмаларыннан** (V-IX гасырлар)

- Ишеңә изге фикердә бул,
- Бу яхшылык китерер.
- Ишеңә яман фикердә булсаң,
- Алла җәзаңны бирер.
- Гыйлемне таны, йа бәгем!
- Гыйлем сиңа тиң булыр;
- Белеме булган ул иргә
- Бер көнне бәхет булыр.
- Юлдаш ит изге эшне,
- Күрсәтер туры юлны;
- Кисмәгез кәкре агачны,
- Түбәсендә җимеше бар.

- Болгар чорында педагогикадан өстәл китаплары булып **Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”, Сөләйман Саксини, Әхмәт Ясәви** әсәрләре тора.



# Йосыф Баласагунлы (1016-1070)




- Әсәрләрендә галәм, тереклек, яшәү-үлем, табигать күренешләре турында уйланулар байтак. Вакыт, гомер агышын җил, аккан су белән чагыштыра.

- **Алтын Урда дәүләтендә** дә уку-яза белү һәм язма әдәбият зур әһәмияткә ия була. Бу чордагы мәгърифәтчеләр**: Мәхмүд әл-Болгари, Котб, Хисам Кятиб** һәм башкаларның педагогик эшчәнлекләренең төп юнәлешләре булып үгет-нәсыйхәт һәм дини тәрбия мәсьәләләре тора.



**Казан ханлыгы чоры** мәгрифәтчеләре:Кол Шәриф, Миңлегәрәй, Өмми Камал һ.б

- Аларның яшәү-көнкүрешен сурәтләүдә табигать күренешләре актив кулланыла. Өмми Камалның иҗатында, мәсәлән, шактый гына юлларны пейзаж лирикасы дип атарга мөмкин.



# Ибраһим Хәлфин (1777-1829)



- 1819 елда татар милли мәктәпләре һәм мәдрәсәләре өчен эшчәнлеген камилләштерү максатында “И.И. Хәлфиннең татар мәгарифенә кызыклы фикерләре” дип аталган хезмәтен яза.

# Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889).



Ул мәдрәсәнең уку-укыту эшләрен яңача үзгәртеп кора, укыту программасына тарих, география, математика, астрономия фәннәрен кертә.

# Каюм Насыйри (1825-1902)



- Халкыбыз өчен бик тә кирәкле булган төрле уку әсбаплары, дәреслекләр төзи. Аның  тарафыннан татар теле, рус теле, математика, геометрия, география, ботаника һәм башка фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр бастырыла.

# Хөсәен Фәезхан (1825-1866)




- Татар мәдрәсәләрендә рус гимназиясенең барлык фәннәрен дә, ислам һәм гарәп теле, Көнбатыш телләре, география, табигать белеме, тыйблык, рус теле һәм төрек телләре укытуны яклап чыга.

# Галимҗан Баруди (1857-1921)



Галим яшь буынга фәннең төрле тармакларыннан мәгълүмат бирү, сәүдә һәм сәнәгать эшен ныклы өйрәтү мәсьәләсен күтәреп чыга.

Дини мәдрәсәләрдән баш тартмаган хәлдә, ул “профессор, фәлсәфәчеләр, инженерлар” әзерли торган дөньяви мәктәпләр кирәк дигән фикерне алга сөрә.

# *Ризаэддин Фәхретдин (1858-1936)*




- Ул мәктәптә балаларны тәртипкә, әхлакка өйрәтүче укытучыларның коры сүз белән түгел, ә үзенең шәхси үрнәгендә тәрбияләү осталыгы булырга тиешлеген таләп итә.

“Буш фикерләр вә буш сүзләр белән шөгыльләнүгә караганда, берәр төрле файдалы нәрсә белән шөгыльләнү, янәшә тирәне чолгап алган нәрсәне танып белү, су вә һаваны, туфрак вә утны, үлән вә агачларны, ай вә йолдызларны өйрәнү, гомумән, табигать әхвәлләре белән таныш булырга тырышу яхшырактыр”,- ди

Р.Фәхретдинов

***Каюм Насыйри материаллары буенча төзелгән***
***Ризаэддин бине Фәхреддин нәселе шәҗәрәсе***




---

Кармыш — Чуваш республикасы, Козловка районындагы татар авылы.
Сембер — Ульяновск шәһәре.
Җуынчы, Бакырчы, Кошман — Татарстанның Кайбыч төбәгендәге татар авыллары. (*М. Ә.* искәрмәләре.)

# Йомгаклау

- Мәгърифәтчелеләребез  милләтне агарту, аң-белемле, һөнәрле итү, әхлакый тәрбияләү, уку-укыту системасын үзгәртеп кору, һәм, гомумән, татар тормышын һәрьяклап яңарту идеяләре белән сугарылган мәгърифәтчелек идеологиясе, белән шөгыльләнә, матур әдәбиятны үзенә көчле, үтемле корал итеп алып, аның үсешенә гаять зур этәргеч ясый.